**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биләркүл авыл җирлегенең Биләркүл авылы торак пунктында гражданнар җыены КАРАРЫ**

«10» апрель 2024 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Биләркүл авыл җирлегенең Биләркүл авылы торак пункты гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ**:**

1. Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә», 2024 елның 4 апрелендә узган: «Биләркүл авыл җирлеге Биләркүл торак пункты территориясендә яшәүче, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан тыш балигъ булган һәр кешедән 2024 елда 1500 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Биләркүл авылы чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдалanudагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту;
- урам яктырту җайланмасы;

Биләркүл авылы торак пункты территориясен төзекләндерү;

су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау» мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде.

Халык җыенында рәислек итүче: В.С. Оренбургов

Биләркүл авыл җирлеге башлыгы: В.С.Оренбургов